| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

| **КАРАРЫ**<br>**20.03.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 380** |
|---|---|---|

Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләренең хезмәт торак урыннарын муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшерү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә Торак фондын хосусыйлаштыру турында» 1991 елның 4 июлендәге 1541-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 4 статьясы таләпләре нигезендә, муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыннарын төшерү тәртибен билгеләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Матвеева О. А. мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, Зеленодольск муниципаль районы Советы Татарстан Республикасы муниципаль районы **карар кылды**:

1. Хезмәт торак урыннарын Зеленодольск муниципаль районының муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшерү тәртибе турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**

РАСЛАНГАН
2024 елның 20 мартындагы
Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Советының 380 номерлы карары белән

**ХЕЗМӘТ ТОРАК УРЫННАРЫН**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**МУНИЦИПАЛЬ МАХСУСЛАШТЫРЫЛГАН ТОРАК ФОНДЫННАН**
**ТӨШЕРҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә Торак фондын хосусыйлаштыру турында» 1991 елның 4 июлендәге 1541-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 4 статьясы таләпләре нигезендә эшләнгән һәм хезмәт торак урыннарын Зеленодольск муниципаль районының муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшерү тәртибен регламентлаштыра.

2. Хезмәт торак урыннары муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан түбәндәге очракларда төшерелергә мөмкин:

2.1. хезмәткәрләргә хезмәт торак урыннары биргән оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр җитәкчеләренең үтенечнамәләре буенча, әлеге оешмаларда, учреждениеләрдә, предприятиеләрдә гражданнарның гомуми дәвамлылыгы 10 елдан да ким булмаганда;

2.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлеге башлыгы, Зеленодольск шәһәр прокуроры үтенечнамәләре буенча, эчке эшләр органнарында, прокуратурада хезмәткәрләрнең гомуми хезмәт итү дәвамлылыгы 10 елдан артык булганда;

2.3. хезмәт урыныннан бирелә торган торак белән тәэмин иткән оешмаларда, учреждениеләрдә, предприятиеләрдә яки әлеге тармакта кимендә 10 ел эшләгән гражданнарның гаризалары буенча;

2.4. эш стажларын исәпкә алмыйча, түбәндәге категорияләргә караган гражданнарның гаризалары буенча:

- хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә яисә хезмәт вазифаларын башкарганда һәлак (вафат) булган яки хәбәрсез югалган хәрби хезмәткәрләрнең, вазифаи затларның, эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең һәм аларга тиңләштерелгән затларның гаилә әгъзалары;

- хезмәт урыныннан торак бирелгән һәм соңыннан вафат булган хезмәткәрнең гаилә әгъзалары;

- эш бирүче гаебе белән хезмәт урынында имгәнеп, инвалидлык алган I яки II группа инвалидлар;

- хезмәт вазифаларын үтәү барышында барлыкка килгән һөнәри авыру нәтиҗәсендә инвалидлык алган I яки II группа инвалидлар;

- хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын) үтәгәндә яки хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт бурычларын)үтәү белән бәйле авыру нәтиҗәсендә яралану, контузия яки имгәнү нәтиҗәсендә I яки II группа инвалидлары булган хәрби хезмәткәрләр һәм аларга тиңләштерелгән затлар арасыннан инвалидлар;

- предприятие, учреждение, оешма ябылуга яки хезмәткәрләр санын яисә штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар;

- картлык буенча пенсионерлар;

- махсуслаштырылган торак фондының торак урынын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган «Бинаны торак урын, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария

хәлендә һәм реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында» гы нигезләмәгә ярашлы рәвештә  яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта.

3. Оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр җитәкчеләре һәм (яисә) гражданнар хезмәт торак урыннарын муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшерү өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба - Башкарма комитет) түбәндәге документларны тапшыралар:

- гариза;

- Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе,Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе,тиешле дәүләт органы  җитәкчесенең үтенечнамәсе;

- кәгазь чыганакта тиешле рәвештә таныкланган хезмәт эшчәнлеге ,  хезмәт стажы турында документлар, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән (эш бирүчедә булганда)  имзаланган электрон документ формасында;

- хезмәт шартнамәсенең таныкланган күчермәсе йә хезмәт контрактының таныкланган күчермәсе;

- хезмәт торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документлар;

- гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен раслый торган документлар;

- Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсе тарафыннан гариза бирүче вәкаләтле органга мөрәҗәгать иткән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча бирелгән гражданның күчемсез милек объектларына, шулай ук гаиләнең барлык күченеп килүче әгъзаларына, шул исәптән балигъ булмаганнарга, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә хокукны теркәү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында сорала торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә;

- дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентаризация буенча вәкаләтле оешманың 2000 елның 1 гыйнварына кадәр гражданның,  шулай ук гаиләнең барлык күченеп килүче  әгъзаларына, шул исәптән балигъ булмаганнарга тиешле муниципаль берәмлек территориясендә күчемсез милек объектларына милек хокукы булу (булмау) турында мәгълүматны үз эченә алган белешмәсе;

- йорт яшәү өчен яраксыз(авария хәлендә) дип танылган очракта, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты ведомствоара комиссиясенең йортны яшәү өчен яраксыз (авария хәлендә) дип тану турындагы бәяләмәсе.

4. Башкарма комитет түбәндәге очракларда муниципаль хезмәт торак урыннарын махсуслаштырылган торак фондыннан  төшерүдән   баш тарту турында карар кабул итә:

- әгәр хокуксыз зат мөрәҗәгать итсә (граждан хезмәт торак урынында теркәлмәгән);

- хезмәт торак урыны Зеленодольск муниципаль районының муниципаль милек составына кермәсә;

- әгәр  әлеге нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаса, яки документларның тулы булмаган пакеты тапшырылса;

- әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очраклардан тыш, әлеге тармактагы предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә гражданнарның эш дәвамлылыгы 10 елдан кимрәк булса;

- әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очраклардан тыш, эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең (хәрби хезмәткәрләрнең) хезмәт итүенең гомуми дәвамлылыгы, 10 елдан кимрәк булса;

- хезмәт урыныннан торак бирелгән гражданин даими яшәү өчен башка урынга күченеп киткән булса;

- әгәр хезмәт торак урыны бирелгән граждан Зеленодольск муниципаль районында бер гаилә әгъзасына билгеләнгән исәп-хисап нормасыннан күбрәк торак белән тәэмин ителсә;

- әгәр соңгы биш ел эчендә торак шартлары махсус рәвештә начар хәлгә китерелгән булса.

5. Хезмәт торак урынын муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшерүдән баш тарту турындагы карар мөрәҗәгать итүчегә, баш тартуның сәбәбен күрсәтеп, язма рәвештә 30 көн эчендә җиткерелә.

Баш тарту турындагы карар суд тәртибендә дәгъваланырга мөмкин.

6. Хезмәт торак урыннарын муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан төшереү турындагы карарлар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә, ул мөрәҗәгать итүчегә 30 көн эчендә язма рәвештә җиткерелә.

7. Торак урынын махсуслаштырылган торак фондыннан төшереп калдыру турындагы карар нигезендә Башкарма комитет, Россия Федерациясе законнары таләпләре буенча, әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар белән торак урынны социаль наем шартнамәсен төзү турында карар кабул итә.